СОВЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

14.12.2020 г.Зеленодольск № 24

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советының 2018 елның 9 июлендәге «Зеленодольск муниципаль районы территориясендә аренда хокукында инвалидларга һәм инвалид балалары булган гаиләләргә җир кишәрлекләрен беренче чиратта бирү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 308 номерлы карары белән расланган Зеленодольск муниципаль районы территориясендә аренда хокукында инвалидларга һәм инвалид балалары булган гаиләләргә җир кишәрлекләрен беренче чиратта бирү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Конституциясенең 17 статьясын, «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль законын нигезләмәләре нигезендә һәм 2020 елның 12 октябрендәге 02-01-18/2020 номерлы Зеленодольск шәһәр прокуратурасы протестын гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советы **карар итте**:

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советының 2018 елның 9 июлендәге «Зеленодольск муниципаль районы территориясендә инвалидларга һәм инвалид балалары булган гаиләләргә аренда хокукында җир кишәрлекләрен беренче чиратта бирү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 308 номерлы карары белән расланган Зеленодольск муниципаль районы территориясендә инвалидларга һәм инвалид балалары булган гаиләләргә аренда хокукында җир кишәрлекләрен беренче чиратта бирү тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 1 пунктның 1.1 пунктчасында «шәхси» «, дача хуҗалыгы» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.2 2 пунктның 2.1.1 пунктчасында «Зеленодольск муниципаль районы составына керүче» сүзләреннән соң «йә Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы чикләрендә яшәү урыны буенча башка юридик фактлар нигезендә билгеләнгән» сүзләрен өстәргә;

1.3. 2 пунктның 2.1.5 пунктчасында «шәхси», «, дача хуҗалыгы» сүзләрен төшереп калдырырга.

1.4. 2 пунктның 2.3 пунктчасында «Зеленодольск муниципаль районы составына керүче» сүзләреннән соң «йә Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы чикләрендә яшәү урыны буенча башка юридик фактлар нигезендә билгеләнгән» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмати сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

**Зеленодольск муниципаль районы**
**Башлыгы, Совет рәисе** **М.П. Афанасьев**

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН СОВЕТ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
ИНН 1648017831 КПП 164801001
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ